**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7835**
**27.12.2018**

Башкарма комитетның аерым
карарлары үз көчен югалткан
дип тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсендәге 1 бүлекнең 24 пункты, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ санлы Федераль законның 8 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.17, 5.21, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) 2007 елның 14 февралендә «Челнинские известия» газетасының 27-28 саннарында басылып чыккан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең «Яр Чаллы шәһәре территориясендә кара һәм төсле металл ватыкларын әзерләү, эшкәртү һәм реализацияләү эшчәнлеген тәртипкә салу турында» 2007 елның 7 февралендәге 332 нче карары;

2) Яр Чаллы шәһәре хакимияте башлыгының «Төсле металл ватыкларын һәм калдыкларын җыю һәм реализацияләү белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыруга контрольне көчәйтү турында» 2000 елның 22 февралендәге 185 нче карары.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны бастырып чыгаруны һәм аны Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин